**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 6 июнь № 345

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 9 март, 133 нче; 2016 ел, 8 май, 286 нчы; 2016 ел, 21 июнь, 419 нчы; 2016 ел, 4 октябрь, 715 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 968 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Тәртипнең I бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Социаль хезмәт күрсәтүне оештыруның гомуми мәсьәләләре

1.1.1. Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль

хезмәтләр күрсәтү тәртибе (алга таба – Тәртип) Татарстан Республикасында Россия Федерациясе гражданнарына, Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга, качакларга (алга таба – гражданнар, граждан) социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүне регламентлаштыра.

Бу Тәртипнең гамәле Татарстан Республикасында картлар һәм инвалидлар өчен интернат йортларда (пансионатларда), картлар һәм инвалидлар өчен махсус интернат йортларда, билгеле бер яшәү һәм эшләү урыны булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәкләрендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү өлешендә шулай ук гадәттән тыш массакүләм тәртиптә Россия Федерациясе территориясенә килгән һәм Россия Федерациясе территориясендә качаклар дип тануны яисә Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча качу урыны бирүне сораган яки качак статусын яки вакытлыча качу урыны турында таныклык алган Украина территориясендә даими яшәүче Украина гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар арасыннан затларга кагыла.

Стационар формада социаль хезмәтләр күрсәтү социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыга социаль хезмәт күрсәтү оешмасында даими, вакытлыча яки биш көн (атнага) тәүлек әйләнәсендә яшәгән шартларда социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы нигезендә социаль хезмәтләр комплексын күрсәтү аша гамәлгә ашырыла.

Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәткәндә файдаланыла торган документларның бертип формалары Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан раслана, моңа законнар нигезендә федераль дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләнә торган документлар формалары керми.

Стационар формада социаль хезмәт күрсәтүгә кабул ителә торган гражданнар үзләренә күрсәтелә торган социаль хезмәтләр исемлеге һәм эчтәлеге, аларны күрсәтү шартлары һәм кагыйдәләре, шулай ук стационар формада социаль хезмәтләр күрсәткәндә гражданнарның үз-үзләрен тоту кагыйдәләре белән танышырга тиеш.

Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәткәндә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче законнар нигезендә түбәндәгеләрне эшләргә тиеш:

кеше һәм граждан хокукларын сакларга;

шәхеснең кагылгысызлыгын һәм социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучылар иминлеген тәэмин итәргә;

хезмәт күрсәтү белән тәэмин итүче үз эшчәнлеген аларга таянып гамәлгә ашыра һәм социаль хезмәтләр күрсәтүдә нигез итеп файдалана торган хокук билгели торган документлары белән социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларны (аларның законлы вәкилләрен) таныштыруны тәэмин итәргә;

социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның шәхси һәм кыйммәтле әйберләренең сакланышын тәэмин итәргә;

социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларга куркынычсызлык техникасы, янгын куркынычсызлыгы, бирелә торган приборларны һәм җиһазларны эксплуатацияләү кагыйдәләре турында мәгълүмат бирергә;

социаль хезмәтләр күрсәткәндә санитария-гигиена таләпләренә туры килә торган шартларны, шулай ук тиешенчә карауны тәэмин итәргә;

социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның социаль хезмәт күрсәтүгә хокукларын тормышка ашыруга бәйле башка вазыйфаларны башкарырга.

Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучылар социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләрнең һәм социаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәлләр кылмауларына) карата законнар нигезендә судка кадәр һәм (яки) суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

Социаль хезмәтләр күрсәтүдән социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында файдаланганда социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучылар социаль хезмәтләр күрсәтүдән баш тартырга хокуклы.

Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыга социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүдән баш тартырга хокуклы, шул исәптән вакытлыча, аның вәкаләтле медицина оешмасы бәяләмәсе белән расланган медицина ягыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдалануына каршы килә торган күрсәткечләре булуга бәйле рәвештә, шулай ук социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучы гамәлдәге законнар нигезендә шәхсән кертергә тиеш булган социаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле мәгълүматларны һәм документларны социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучы кертмәгән очракта.

Бу Тәртиптә билгеләнгән саннан һәм (яки) күләмнән тыш күрсәтелә торган социаль хезмәтләргә гражданнар законнар нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче белән төзелгән шартнамәдә билгеләнә торган шартларда түли.

1.1.2. Стационар социаль хезмәтләр күрсәтүгә чираттан тыш кабул итү хокукына түбәндәгеләр ия:

хәрби хәрәкәтләр инвалидлары;

Бөек Ватан сугышы инвалидлары;

хәрби хезмәт вазыйфаларын (хезмәт вазыйфаларын) үтәгәндә яралану, контузия алу яки имгәнү сәбәпле инвалид калган эчке эшләр органнары, Дәүләт янгынга каршы хезмәте, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнары хәрби хезмәткәрләре һәм рядовой состав һәм җитәкче составы затлары;

хәрби хезмәт үткән хәрби хезмәткәрләр (хәрби частьларда тәрбияләнүчеләр һәм юнгаларны кертеп) яисә гражданнар сугышы чорында, Бөек Ватан сугышы чорында яки Ватанны саклау буенча башка хәрби операцияләр вакытында хәрәкәттәге армия составына кергән хәрби частьларда, штабларда һәм учреждениеләрдә вакытлыча булган хәрби хезмәткәрләр, шул исәптән запаска (отставкага) чыккан, шулай ук партизаннар һәм гражданнар сугышы чорында яки Бөек Ватан сугышы чорында СССРның вакытлыча оккупацияләнгән территорияләрендә эшләгән яшерен оешмалар әгъзалары;

оборонасында катнашу хәрәкәттәге армия хәрби частьләренең хәрби хезмәткәрләре өчен билгеләнгән ташламалы шартларда пенсияләр билгеләү өчен тиешле еллар эшләгәнгә исәпләнә торган шәһәрләрдә Бөек Ватан сугышы чорында

хәрби хезмәт үткән эчке эшләр органнары һәм дәүләт иминлеге органнары хәрби хезмәткәрләре, шул исәптән запаска (отставкага) чыккан, рядовой состав һәм җитәкче составы затлары;

Бөек Ватан сугышы чорында хәрәкәттәге армия составына кергән хәрби частьларда, штабларда һәм учреждениеләрдә штат вазыйфалары биләгән яисә әлеге чорда оборонасында катнашу хәрәкәттәге армия хәрби частьләренең хәрби хезмәткәрләре өчен билгеләнгән ташламалы шартларда пенсияләр билгеләү өчен тиешле еллар эшләгәнгә исәпләнә торган шәһәрләрдә булган армия һәм флот, гаскәрләр һәм эчке эшләр органнары, дәүләт иминлеге органнарының ялланган составы затлары;

Бөек Ватан сугышы чорында хәрәкәттәге армия составына кергән хәрби частьларда, дошман тылында яки башка дәүләтләр территорияләрендә махсус йөкләмәләр үтәгән разведка, контрразведка хезмәткәрләре;

Бөек Ватан сугышы чорында Кызыл Армия сафларындагы затлар сыйфатында күчерелгән һәм хәрәкәттәге фронтларның тыл чикләрендә яки хәрәкәттәге флотларның операция зоналары чикләрендә армия һәм флот мәнфәгатьләрендә бурычлар үтәгән предприятиеләр һәм хәрби объектлар, халык комиссариатлары, ведомстволар хезмәткәрләре, шулай ук Бөек Ватан сугышы чорында хәрәкәттәге армиягә командировкага җибәрелгән учреждениеләр һәм оешмалар (шул исәптән мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре һәм оешмалары) хезмәткәрләре, үзәк газеталар, журналлар, ТАСС, Совинформбюро һәм радио корреспондентлары, Документаль фильмнар (кинохроника) үзәк студиясе кинооператорлары;

Бөек Ватан сугышы чорында дошман десантларына каршы көрәш буенча хәрби операцияләрдә һәм хәрәкәттәге армия составына кергән хәрби частьлар белән берлектә хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан, шулай ук 1944 елның 1 гыйнварыннан 1951 елның 31 декабренә кадәрге чорда Украина, Белоруссия, Литва, Латвия һәм Эстония территорияләрендә милли подпольены бетерү буенча хәрби операцияләрдә катнашкан эчке эшләр органнары һәм дәүләт иминлеге органнары хәрби хезмәткәрләре, шул исәптән запаска (отставкага) чыккан, рядовой состав һәм җитәкче составы затлары, истребительләр батальоннары, взводлар һәм халыкны яклау отрядлары гаскәриләре һәм команда составы. Бөек Ватан сугышы чорында хәрәкәттәге флот составына кермәгән бүлекчәләрдә хәрби траллау операцияләрендә катнашкан, шулай ук 1941 елның 22 июненнән 1945 елның 9 маена кадәрге чорда СССРның Осоавиахим оешмалары һәм җирле хакимият органнары тарафыннан территорияләрне һәм объектларны миналардан арындыру, сугыш кирәк-яраклары һәм хәрби техника җыю өчен җәлеп ителгән затлар;

партизаннар отрядлары, яшерен төркемнәр, Бөек Ватан сугышы чорындагы фашистларга каршы башка формированиеләр составында башка дәүләтләр территорияләрендә фашист Германиясе һәм аның союздашларына каршы хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан затлар;

«Ленинград оборонасы өчен» медале белән бүләкләнгән затлар, 1941 – 1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы чорында хәрби хәрәкәтләргә бәйле яралану, контузия алу яки имгәнү сәбәпле балачактан инвалид;

1941 елның 22 июненнән 1945 елның 3 сентябренә кадәрге чорда кимендә алты ай хәрәкәттәге армия составына кермәгән хәрби частьларда, учреждениеләрдә,

хәрби уку йортларында хәрби хезмәт үткән, гомуми авырулар, хезмәттә алган имгәнү яки башка сәбәпләр аркасында инвалид калган хәрби хезмәткәрләр (инвалидлык аларның хокукка каршы гамәлләре аркасында барлыкка килгән затлардан тыш), шул исәптән запаска (отставкага) чыккан хәрби хезмәткәрләр; әлеге чордагы хезмәте өчен СССР орденнары яки медальләре белән бүләкләнгән хәрби хезмәткәрләр;

«Блокадалы Ленинградта яшәүчегә» билгесе белән бүләкләнгән затлар.

1.1.3. Стационар социаль хезмәтләр күрсәтүгә беренче чиратта кабул итү хокукына түбәндәгеләр ия:

һәлак булган (үлгән) Бөек Ватан сугышы инвалидының, Бөек Ватан сугышында катнашучы, хәрби хәрәкәтләр инвалиды һәм хәрби хәрәкәтләр ветеранының тәрбиясендә торган һәм Россия Федерациясе пенсия законнары нигезендә туендыручысын югалту сәбәпле пенсия алучы (аны алу хокукына ия) аның хезмәткә яраксыз хатыны (хезмәткә яраксыз ире);

хәрби хезмәт вазыйфаларын (хезмәт вазыйфаларын) үтәгәндә һәлак булган эчке эшләр органнары, Дәүләт янгынга каршы хезмәте, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнары һәм дәүләт иминлеге органнары хәрби хезмәткәренең, рядовой состав һәм җитәкче составы затының тәрбиясендә торган һәм Россия Федерациясе пенсия законнары нигезендә туендыручысын югалту сәбәпле пенсия алучы (аны алу хокукына ия) аның хезмәткә яраксыз хатыны (хезмәткә яраксыз ире);

әсирлектә һәлак булган, әлеге хәрби хезмәткәрне хәрби частьлар исемлекләреннән чыгарган вакыттан башлап, законнарда билгеләнгән тәртиптә хәрби хәрәкәтләр районнарында хәбәрсез югалган дип танылган хәрби хезмәткәрнең тәрбиясендә торган һәм Россия Федерациясе пенсия законнары нигезендә туендыручысын югалту сәбәпле пенсия алучы (аны алу хокукына ия) аның хезмәткә яраксыз хатыны (хезмәткә яраксыз ире);

җирле һава һөҗүменә каршы оборонаның объект һәм һәлакәт командалары саклану төркемнәренең шәхси составы арасыннан Бөек Ватан сугышында һәлак булган затның тәрбиясендә торган һәм Россия Федерациясе пенсия законнары нигезендә туендыручысын югалту сәбәпле пенсия алучы (аны алу хокукына ия) аның хезмәткә яраксыз хатыны (хезмәткә яраксыз ире);

Ленинград шәһәре госпитальләре һәм хастаханәләре хезмәткәрләре арасыннан Бөек Ватан сугышында һәлак булган затның тәрбиясендә торган һәм Россия Федерациясе пенсия законнары нигезендә туендыручысын югалту сәбәпле пенсия алучы (аны алу хокукына ия) аның хезмәткә яраксыз хатыны (хезмәткә яраксыз ире);

күчеп китәргә мәҗбүр булган даими карап торуга мохтаҗ зат (өлкән яки инвалид).

Хезмәткә яраклы булуга, тәрбиядә торуга, пенсия яки эш хакы алуга бәйсез рәвештә стационар социаль хезмәтләр күрсәтүгә беренче чиратта кабул итү хокукына түбәндәгеләр ия:

һәлак булган (үлгән) Бөек Ватан сугышы инвалидларының, хәрби хәрәкәтләр инвалидларының кабат кияүгә чыкмаган (өйләнмәгән) хатыннары (ирләре);

һәлак булган (үлгән) Бөек Ватан сугышында катнашучыларның кабат кияүгә чыкмаган (өйләнмәгән) хатыннары (ирләре);

һәлак булган (үлгән) хәрби хәрәкәтләр ветераннарының кабат кияүгә чыкмаган (өйләнмәгән), ялгыз яшәүче яки балигъ булмаган балалары белән, яисә 18 яше тулганчы инвалид калган 18 яшьтән өлкәнрәк балалары белән, яисә 23 яше тулмаган һәм мәгариф оешмаларында көндезге уку формасы буенча белем ала торган балалары белән яшәүче хатыннары (ирләре);

җирле һава һөҗүменә каршы оборонаның объект һәм һәлакәт командалары саклану төркемнәренең шәхси составы арасыннан Бөек Ватан сугышында һәлак булган затларның, Ленинград шәһәре госпитальләре һәм хастаханәләренең һәлак булган хезмәткәрләренең кабат кияүгә чыкмаган (өйләнмәгән) хатыннары (ирләре);

хәрби хезмәт вазыйфаларын (хезмәт вазыйфаларын) үтәгәндә һәлак булган эчке эшләр органнары, Дәүләт янгынга каршы хезмәте, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнары һәм дәүләт иминлеге органнары хәрби хезмәткәрләренең, рядовой состав һәм җитәкче составы затларының кабат кияүгә чыкмаган (өйләнмәгән) хатыннары (ирләре);

әсирлектә һәлак булган, әлеге хәрби хезмәткәрләрне хәрби частьлар исемлекләреннән чыгарган вакыттан башлап, законнарда билгеләнгән тәртиптә хәрби хәрәкәтләр районнарында хәбәрсез югалган дип танылган хәрби хезмәткәрләрнең кабат кияүгә чыкмаган (өйләнмәгән) хатыннары (ирләре);

һәлак булган (үлгән) Бөек Ватан сугышы инвалидларының, хәрби хәрәкәтләр инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарының ата-аналары;

хәрби хезмәт вазыйфаларын (хезмәт вазыйфаларын) үтәгәндә һәлак булган эчке эшләр органнары, Дәүләт янгынга каршы хезмәте, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнары һәм дәүләт иминлеге органнары хәрби хезмәткәрләренең, рядовой состав һәм җитәкче составы затларының ата-аналары;

әсирлектә һәлак булган, әлеге хәрби хезмәткәрләрне хәрби частьлар исемлекләреннән чыгарган вакыттан башлап, законнарда билгеләнгән тәртиптә хәрби хәрәкәтләр районнарында хәбәрсез югалган дип танылган хәрби хезмәткәрләрнең ата-аналары;

җирле һава һөҗүменә каршы оборонаның объект һәм һәлакәт командалары саклану төркемнәренең шәхси составы арасыннан Бөек Ватан сугышында һәлак булган (үлгән) затларның, шулай ук Ленинград шәһәре госпитальләре һәм хастаханәләренең һәлак булган хезмәткәрләренең ата-аналары.

1.1.4. Стационар социаль хезмәтләр күрсәтүгә кабул иткәндә өстенлеккә түбәндәгеләр ия:

1) 1941 елның 22 июненнән 1945 елның 3 сентябренә кадәрге чорда кимендә алты ай хәрәкәттәге армия составына кермәгән хәрби частьларда, учреждениеләрдә, хәрби уку йортларында хәрби хезмәт үткән, шул исәптән запаска (отставкага) чыккан хәрби хезмәткәрләр; әлеге чордагы хезмәте өчен СССР орденнары яки медальләре белән бүләкләнгән хәрби хезмәткәрләр;

2) Бөек Ватан сугышы чорында хәрәкәттәге фронтларның тыл чикләрендә, хәрәкәттәге флотларның операция зоналары чикләрендә, тимер юллар һәм автомобиль юлларының фронт буендагы участокларында һава һөҗүменә каршы

оборона объектларында, җирле һава һөҗүменә каршы оборонада, оборона корылмалары, хәрби-диңгез базалары, аэродромнар һәм башка хәрби объектлар төзелешендә эшләгән затлар;

3) Бөек Ватан сугышы башланганда башка дәүләтләр портларында иректән мәхрүм ителгән транспорт флоты суднолары экипажлары әгъзалары;

4) Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация тәэсиренә дучар булган һәм нурланышның 25 сЗв (бэр) артык гомуми (җыелган) эффектив дозасын алган гражданнар;

5) Чернобыль һәлакәте аркасында радиация тәэсиренә яки Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәләрен бетерү эшләренә бәйле нурланыш авыруы яки башка авырулар эләктергән яки кичергән гражданнар;

6) түбәндәгеләр арасыннан булган Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендә инвалидлар:

Чернобыль АЭСында ябык зона чикләрендә һәлакәт нәтиҗәләрен бетерүдә катнашкан яисә Чернобыль АЭСында эксплуатациядә яки башка эшләрдә мәшгуль гражданнар (шул исәптән вакытлыча җибәрелгән яки командировкага җибәрелгән);

махсус җыеннарга чакырылган һәм Чернобыль һәлакәте нәтиҗәләрен бетерүгә бәйле эшләрне башкаруга җәлеп ителгән хәрби хезмәткәрләр һәм хәрби хезмәттә булырга тиешле затлар, дислокация урынына һәм башкарылган эшләргә бәйсез рәвештә, шулай ук Чернобыль АЭСының ябык зонасында хезмәт үткән (үтүче) эчке эшләр органнарының, Дәүләт янгынга каршы хезмәтенең җитәкче һәм рядовой составы затлары;

Чернобыль АЭСының ябык зонасыннан эвакуацияләнгән һәм күченү зонасыннан күчеп киткән яисә эвакуация турында карар кабул ителгәннән соң әлеге зоналардан үз ихтыяры белән киткән гражданнар;

Чернобыль һәлакәте аркасында зыян күргән кешеләрнең гомерен коткару өчен сөяк миен биргән гражданнар, сөяк миен күчереп утырткан мизгелдән соң узган вакытка һәм моңа бәйле аларның инвалидлыгы үсеш алган вакытка бәйсез рәвештә;

7) Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә һәлак булган, нурланыш авыруыннан һәм Чернобыль һәлакәтенә бәйле барлыкка килгән башка авырулардан үлгән гражданнар арасыннан булган туендыручысын югалткан гаиләләр әгъзалары, шулай ук Чернобыль һәлакәте аркасында вафат булган инвалидларның гаиләләре;

8) 1986 – 1987 елларда Чернобыль АЭСының ябык зонасы чикләрендә Чернобыль һәлакәте нәтиҗәләрен бетерү эшләрендә катнашкан яки әлеге чорда халыкны, матди кыйммәтләрне, авыл хуҗалыгы хайваннарын эвакуацияләүгә бәйле эшләрдә һәм эксплуатациядә яки Чернобыль АЭСындагы башка эшләрдә мәшгуль булган гражданнар (шул исәптән вакытлыча җибәрелгән яки командировкага җибәрелгән); махсус җыеннарга чакырылган һәм әлеге чорда Чернобыль АЭСының ябык зонасы чикләрендә Чернобыль һәлакәте нәтиҗәләрен бетерүгә бәйле эшләрне башкару өчен җәлеп ителгән хәрби хезмәткәрләр һәм хәрби хезмәттә булырга тиешле затлар, шул исәптән граждан авиациясенең очу-күтәрелү, инженер-техник составларын кертеп, дислокация урынына һәм башкарылган эшләргә бәйсез рәвештә; Чернобыль АЭСының ябык зонасында 1986 – 1987 елларда хезмәт үткән эчке эшләр органнарының җитәкче һәм рядовой составы затлары; хәрби җыеннарга чакырылган һәм 1988 – 1990 елларда «Укрытие» объекты буенча эшләрдә катнашкан гражданнар, шул исәптән хәрби хезмәткәрләр һәм хәрби хезмәттә

булырга тиешле затлар; Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендә зыян күргән һәм ионлаштыра торган нурланыш чыганаклары булган затларга 1986 елның 26 апреленнән 30 июненә кадәрге чорда медицина ярдәме һәм хезмәтләр күрсәткәндә нурланышның нормативтан тыш дозаларын алган кече һәм урта медицина персоналы, табиблар һәм дәвалау учреждениеләренең башка хезмәткәрләре (һөнәри эшчәнлекләре үткәрелә торган эшнең профиленә туры килә торган эш урынында радиация хәлләре шартларында ионлаштыра торган нурланышларның теләсә нинди төрләре белән эшләүгә бәйле булган затлардан тыш);

9) Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәләрен бетерүдә катнашкан, вафат булган затларның гаилә әгъзалары, шул исәптән тол калган хатыннары (тол ирләре);

10) 1988 – 1990 елларда Чернобыль АЭСында ябык зона чикләрендә Чернобыль һәлакәте нәтиҗәләрен бетерү эшләрендә катнашкан яки әлеге чорда эксплуатациядә яки Чернобыль АЭСындагы башка эшләрдә мәшгуль булган гражданнар (шул исәптән вакытлыча җибәрелгән яки командировкага җибәрелгән); махсус җыеннарга чакырылган һәм әлеге елларда Чернобыль һәлакәте нәтиҗәләрен бетерүгә бәйле эшләрне башкару өчен җәлеп ителгән хәрби хезмәткәрләр һәм хәрби хезмәттә булырга тиешле затлар, дислокация урынына һәм башкарылган эшләргә бәйсез рәвештә, шулай ук Чернобыль АЭСының ябык зонасында 1988 – 1990 елларда хезмәт үткән эчке эшләр органнарының җитәкче һәм рядовой составы затлары;

11) Чернобыль АЭСының ябык зонасындагы эшләрдә нурланыш тәэсиренә бәйле рәвештә һөнәри авырулар эләктергән эшчеләр һәм хезмәткәрләр, шулай ук хәрби хезмәткәрләр, эчке эшләр органнарының, Дәүләт янгынга каршы хезмәтенең җитәкче һәм рядовой составы затлары;

12) 1986 елда Чернобыль АЭСындагы ябык зонадан эвакуацияләнгән (шул исәптән үз ихтыяры белән киткән) яки күчеп киткән (күчеп китә торган), шул исәптән 1986 елда һәм аннан соңгы елларда күченү зонасыннан үз ихтыяры белән киткән гражданнар, балаларны, шул исәптән эвакуация вакытында ана карынындагы үсеш чорында булган (булучы) балаларны кертеп;

13) Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендә яки атасы яисә анасының радиоактив нурланышы генетик нәтиҗәләре китереп чыгарган авырулар белән авыручы балалар һәм яшүсмерләр; Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендә яки атасы яисә анасының радиоактив нурланышы генетик нәтиҗәләре китереп чыгарган авырулар үсеш алган очракта балаларының киләчәк буыннары;

14) 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария нәтиҗәләрен бетерү эшләрендә 1957 – 1958 елларда турыдан-туры катнашкан, махсус җыеннарга чакырылган гражданнар (шул исәптән вакытлыча җибәрелгән яки командировкага җибәрелгән), хәрби хезмәткәрләр һәм хәрби хезмәттә булырга тиешле затларны кертеп, эчке эшләр органнары, дәүләт иминлеге органнары, граждан оборонасы органнарының җитәкче һәм рядовой составы затлары, шулай ук 1949 – 1956 елларда Теча елгасы буендагы радиоактивлар белән пычранган территорияләрне саклау чаралары үткәрү һәм тергезү эшләрендә мәшгуль булган, махсус җыеннарга чакырылган гражданнар, хәрби хезмәткәрләр һәм хәрби хезмәттә булырга тиешле затларны кертеп, эчке эшләр органнары, дәүләт иминлеге органнары, граждан оборонасы органнарының җитәкче һәм рядовой составы затлары;

15) 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария нәтиҗәләрен бетерү эшләрендә 1959 – 1961 елларда турыдан-туры катнашкан, махсус җыеннарга чакырылган гражданнар (шул исәптән вакытлыча җибәрелгән яки командировкага җибәрелгән), хәрби хезмәткәрләр һәм хәрби хезмәттә булырга тиешле затларны кертеп, эчке эшләр органнары, дәүләт иминлеге органнары, граждан оборонасы органнарының җитәкче һәм рядовой составы затлары, шулай ук 1957 – 1962 елларда Теча елгасы буенда радиоактивлар белән пычранган территорияләрне саклау чаралары үткәрү һәм тергезү эшләрендә мәшгуль булган, махсус җыеннарга чакырылган гражданнар, хәрби хезмәткәрләр һәм хәрби хезмәттә булырга тиешле затларны кертеп, эчке эшләр органнары, дәүләт иминлеге органнары, граждан оборонасы органнарының җитәкче һәм рядовой составы затлары;

16) 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм Теча елгасына радиоактив калдыклар агызу аркасында радиация тәэсиренә дучар булган эвакуацияләнгән (күченгән), шулай ук торак пунктлардан үз ихтыяры белән киткән (шул исәптән эвакуация (күченү) өлешчә башкарылган торак пунктлар чикләрендә эвакуацияләнгән (күченгән)) гражданнар, балаларны, шул исәптән эвакуация (күченү) вакытында ана карынындагы үсеш чорында булган балаларны кертеп, шулай ук 1957 елда радиоактив пычрану зонасыннан эвакуацияләнгән хәрби хезмәткәрләр, хәрби частьләрнең ялланган составы һәм махсус контингент. Үз ихтыяры белән киткән гражданнарга 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария аркасында радиация тәэсиренә дучар булган торак пунктлардан 1957 елның 29 сентябреннән 1960 елның 31 декабренә кадәр (31 декабрьне дә кертеп) киткән, шулай ук Теча елгасына радиоактив калдыклар агызу аркасында радиация тәэсиренә дучар булган торак пунктлардан 1949 елдан башлап 1962 елга кадәр (1962 елны да кертеп) киткән (шул исәптән күченү өлешчә булган торак пунктлар чикләрендә күченеп киткән) гражданнар керә;

17) нурланыш авыруы, 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм Теча елгасына радиоактив калдыклар агызу нәтиҗәсендә радиация тәэсире аларны барлыкка китергән яки көчәйткән авырулар исемлегенә керә торган башка авырулар эләктергән яисә радиация тәэсире нәтиҗәсендә инвалид булган:

хәзерге вакытта нурланышның уртача еллык эффектив дозасы 1 мЗв (0,1 бэр) артык тәшкил иткән (әлеге җирлек өчен табигый радиация фоны дәрәҗәсеннән өстәмә) 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм Теча елгасына радиоактив калдыклар агызу аркасында радиация тәэсиренә дучар булган торак пунктларда яшәүче гражданнар;

1949 – 1956 елларда Теча елгасына радиоактив калдыклар агызу аркасында радиация тәэсиренә дучар булган торак пунктларда яшәгән һәм нурланышның 35 сЗв (бэр) артык җыелган эффектив дозасын алган гражданнар;

1949 – 1956 елларда Теча елгасына радиоактив калдыклар агызу аркасында радиация тәэсиренә дучар булган торак пунктларда яшәгән һәм нурланышның 7 сЗв (бэр) артык, әмма күп дигәндә 35 сЗв (бэр) җыелган эффектив дозасын алган гражданнар;

хәзерге вакытта нурланышның уртача еллык эффектив дозасы 1 мЗв (0,1 бэр) артык тәшкил иткән (әлеге җирлек өчен табигый радиация фоны дәрәҗәсеннән өстәмә) 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм Теча елгасына

радиоактив калдыклар агызу аркасында радиация тәэсиренә дучар булган торак пунктлардан яңа яшәү урынына үз ихтыяры белән киткән гражданнар;

18) нурланыш авыруы, 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм Теча елгасына радиоактив калдыклар агызу нәтиҗәсендә радиация тәэсире аларны барлыкка китергән яки көчәйткән авырулар исемлегенә керә торган башка авырулар эләктергән яисә радиация тәэсире нәтиҗәсендә инвалид булганнар арасыннан туендыручысын югалткан гаиләләр әгъзалары:

1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария нәтиҗәләрен бетерү эшләрендә 1957 – 1958 елларда турыдан-туры катнашкан, махсус җыеннарга чакырылган гражданнар (шул исәптән вакытлыча җибәрелгән яки командировкага җибәрелгән), хәрби хезмәткәрләр һәм хәрби хезмәттә булырга тиешле затларны кертеп, эчке эшләр органнары, дәүләт иминлеге органнары, граждан оборонасы органнарының җитәкче һәм рядовой составы затлары, шулай ук 1949 – 1956 елларда Теча елгасы буендагы радиоактивлар белән пычранган территорияләрне саклау чаралары үткәрү һәм тергезү эшләрендә мәшгуль булган, махсус җыеннарга чакырылган гражданнар, хәрби хезмәткәрләр һәм хәрби хезмәттә булырга тиешле затларны кертеп, эчке эшләр органнары, дәүләт иминлеге органнары, граждан оборонасы органнарының җитәкче һәм рядовой составы затлары;

1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария нәтиҗәләрен бетерү эшләрендә 1959 – 1961 елларда турыдан-туры катнашкан, махсус җыеннарга чакырылган гражданнар (шул исәптән вакытлыча җибәрелгән яки командировкага җибәрелгән), хәрби хезмәткәрләр һәм хәрби хезмәттә булырга тиешле затларны кертеп, эчке эшләр органнары, дәүләт иминлеге органнары, граждан оборонасы органнарының җитәкче һәм рядовой составы затлары, шулай ук 1957 – 1962 елларда Теча елгасы буенда радиоактивлар белән пычранган территорияләрне саклау чаралары үткәрү һәм тергезү эшләрендә мәшгуль булган, махсус җыеннарга чакырылган гражданнар, хәрби хезмәткәрләр һәм хәрби хезмәттә булырга тиешле затларны кертеп, эчке эшләр органнары, дәүләт иминлеге органнары, граждан оборонасы органнарының җитәкче һәм рядовой составы затлары;

1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм Теча елгасына радиоактив калдыклар агызу аркасында радиация тәэсиренә дучар булган эвакуацияләнгән (күченгән), шулай ук торак пунктлардан үз ихтыяры белән киткән (шул исәптән эвакуация (күченү) өлешчә башкарылган торак пунктлар чикләрендә эвакуацияләнгән (күченгән)) гражданнар, балаларны, шул исәптән эвакуация (күченү) вакытында ана карынындагы үсеш чорында булган балаларны кертеп, шулай ук 1957 елда радиоактив пычрану зонасыннан эвакуацияләнгән хәрби хезмәткәрләр, хәрби частьләрнең ялланган составы һәм махсус контингент. Үз ихтыяры белән киткән гражданнарга 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария аркасында радиация тәэсиренә дучар булган торак пунктлардан 1957 елның 29 сентябреннән 1960 елның 31 декабренә кадәр (31 декабрьне дә кертеп) киткән, шулай ук Теча елгасына радиоактив калдыклар агызу аркасында радиация тәэсиренә дучар булган торак пунктлардан 1949 елдан башлап 1962 елга кадәр (1962 елны да кертеп) киткән (шул исәптән күченү өлешчә булган торак пунктлар чикләрендә күченеп киткән) гражданнар керә;

хәзерге вакытта нурланышның уртача еллык эффектив дозасы 1 мЗв (0,1 бэр) артык тәшкил иткән (әлеге җирлек өчен табигый радиация фоны дәрәҗәсеннән

өстәмә) 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм Теча елгасына радиоактив калдыклар агызу аркасында радиация тәэсиренә дучар булган торак пунктларда яшәүче гражданнар;

1949 – 1956 елларда Теча елгасына радиоактив калдыклар агызу аркасында радиация тәэсиренә дучар булган торак пунктларда яшәгән һәм нурланышның 35 сЗв (бэр) артык җыелган эффектив дозасын алган гражданнар;

1949 – 1956 елларда Теча елгасына радиоактив калдыклар агызу аркасында радиация тәэсиренә дучар булган торак пунктларда яшәгән һәм нурланышның 7 сЗв (бэр) артык, әмма күп дигәндә 35 сЗв (бэр) җыелган эффектив дозасын алган гражданнар;

хәзерге вакытта нурланышның уртача еллык эффектив дозасы 1 мЗв (0,1 бэр) артык тәшкил иткән (әлеге җирлек өчен табигый радиация фоны дәрәҗәсеннән өстәмә) 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм Теча елгасына радиоактив калдыклар агызу аркасында радиация тәэсиренә дучар булган торак пунктлардан яңа яшәү урынына үз ихтыяры белән киткән гражданнар;

19) ата-аналарына радиация тәэсире нәтиҗәсендә авыручы беренче һәм икенче буын балалары:

1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария нәтиҗәләрен бетерү эшләрендә 1957 – 1958 елларда турыдан-туры катнашкан, махсус җыеннарга чакырылган гражданнар (шул исәптән вакытлыча җибәрелгән яки командировкага җибәрелгән), хәрби хезмәткәрләр һәм хәрби хезмәттә булырга тиешле затларны кертеп, эчке эшләр органнары, дәүләт иминлеге органнары, граждан оборонасы органнарының җитәкче һәм рядовой составы затлары, шулай ук 1949 – 1956 елларда Теча елгасы буендагы радиоактивлар белән пычранган территорияләрне саклау чаралары үткәрү һәм тергезү эшләрендә мәшгуль булган, махсус җыеннарга чакырылган гражданнар, хәрби хезмәткәрләр һәм хәрби хезмәттә булырга тиешле затларны кертеп, эчке эшләр органнары, дәүләт иминлеге органнары, граждан оборонасы органнарының җитәкче һәм рядовой составы затлары;

1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария нәтиҗәләрен бетерү эшләрендә 1959 – 1961 елларда турыдан-туры катнашкан, махсус җыеннарга чакырылган гражданнар (шул исәптән вакытлыча җибәрелгән яки командировкага җибәрелгән), хәрби хезмәткәрләр һәм хәрби хезмәттә булырга тиешле затларны кертеп, эчке эшләр органнары, дәүләт иминлеге органнары, граждан оборонасы органнарының җитәкче һәм рядовой составы затлары, шулай ук 1957 – 1962 елларда Теча елгасы буенда радиоактивлар белән пычранган территорияләрне саклау чаралары үткәрү һәм тергезү эшләрендә мәшгуль булган, махсус җыеннарга чакырылган гражданнар, хәрби хезмәткәрләр һәм хәрби хезмәттә булырга тиешле затларны кертеп, эчке эшләр органнары, дәүләт иминлеге органнары, граждан оборонасы органнарының җитәкче һәм рядовой составы затлары;

1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм Теча елгасына радиоактив калдыклар агызу аркасында радиация тәэсиренә дучар булган эвакуацияләнгән (күченгән), шулай ук торак пунктлардан үз ихтыяры белән киткән (шул исәптән эвакуация (күчenү) өлешчә башкарылган торак пунктлар чикләрендә эвакуацияләнгән (күченгән)) гражданнар, балаларны, шул исәптән эвакуация (күчеңү) вакытында ана карынындагы үсеш чорында булган балаларны кертеп, шулай ук 1957 елда радиоактив пычрану зонасыннан эвакуацияләнгән хәрби

хезмәткәрләр, хәрби частьләрнең ялланган составы һәм махсус контингент. Үз ихтыяры белән киткән гражданнарга 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария аркасында радиация тәэсиренә дучар булган торак пунктлардан 1957 елның 29 сентябреннән 1960 елның 31 декабренә кадәр (31 декабрьне дә кертеп) киткән, шулай ук Теча елгасына радиоактив калдыклар агызу аркасында радиация тәэсиренә дучар булган торак пунктлардан 1949 елдан башлап 1962 елга кадәр (1962 елны да кертеп) киткән (шул исәптән күченү өлешчә булган торак пунктлар чикләрендә күченеп киткән) гражданнар керә;

хәзерге вакытта нурланышның уртача еллык эффектив дозасы 1 мЗв (0,1 бэр) артык тәшкил иткән (әлеге җирлек өчен табигый радиация фоны дәрәҗәсеннән өстәмә) 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм Теча елгасына радиоактив калдыклар агызу аркасында радиация тәэсиренә дучар булган торак пунктларда яшәүче гражданнар;

1949 – 1956 елларда Теча елгасына радиоактив калдыклар агызу аркасында радиация тәэсиренә дучар булган торак пунктларда яшәгән һәм нурланышның 35 сЗв (бэр) артык җыелган эффектив дозасын алган гражданнар;

1949 – 1956 елларда Теча елгасына радиоактив калдыклар агызу аркасында радиация тәэсиренә дучар булган торак пунктларда яшәгән һәм нурланышның 7 сЗв (бэр) артык, әмма күп дигәндә 35 сЗв (бэр) җыелган эффектив дозасын алган гражданнар;

хәзерге вакытта нурланышның уртача еллык эффектив дозасы 1 мЗв (0,1 бэр) артык тәшкил иткән (әлеге җирлек өчен табигый радиация фоны дәрәҗәсеннән өстәмә) 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм Теча елгасына радиоактив калдыклар агызу аркасында радиация тәэсиренә дучар булган торак пунктлардан яңа яшәү урынына үз ихтыяры белән киткән гражданнар;

20) атмосферада атом-төш коралы, хәрби радиоактив матдәләр сынауларында һәм мондый коралны кулланып өйрәнүләрдә турыдан-туры катнашучылар, әлеге сынаулар һәм өйрәнүләр фактта тәмамланган көнгә кадәр;

21) штаттан тыш радиация хәлләре шартларында атом-төш коралын һәм атом-төш коралының тидерә торган башка факторлары эшләвен җир астында сынауларда турыдан-туры катнашучылар;

22) су өсте һәм су асты корабльләренең атом-төш җайланмаларында һәм башка хәрби объектларда радиация аварияләрен бетерүдә турыдан-туры катнашучылар;

23) хәрби хезмәткәрләр арасыннан атом-төш зарядларын җыю буенча аерым бүлекчәләрнең шәхси составы;

24) атом-төш коралын җир астында сынауларда, радиоактив матдәләрне җыю һәм күмеп кую эшләрен үткәрүдә һәм оештыруда турыдан-туры катнашучылар;

25) түбәндәгеләр арасыннан туендыручысын югалткан гаиләләр әгъзалары:

атмосферада атом-төш коралы, хәрби радиоактив матдәләр сынауларында һәм мондый коралны кулланып өйрәнүләрдә турыдан-туры катнашучылар, әлеге сынаулар һәм өйрәнүләр фактта тәмамланган көнгә кадәр;

штаттан тыш радиация хәлләре шартларында атом-төш коралын һәм атом-төш коралының тидерә торган башка факторлары эшләвен җир астында сынауларда турыдан-туры катнашучылар;

су өсте һәм су асты корабльләренең атом-төш җайланмаларында һәм башка хәрби объектларда радиация аварияләрен бетерүдә турыдан-туры катнашучылар;

хәрби хезмәткәрләр арасыннан атом-төш зарядларын җыю буенча аерым бүлекчәләрнең шәхси составы;

атом-төш коралын җир астында сынауларда, радиоактив матдәләрне җыю һәм күмеп кую эшләрен үткәрүдә һәм оештыруда турыдан-туры катнашучылар.

1.2. Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләрдән файдалану өчен мөрәҗәгать итү тәртибе

1.2.1. Социаль хезмәт күрсәтү мәсьәләсен карап тикшерү өчен нигез булып гражданның яки аның законлы вәкиленең Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының боерыгы белән раслана торган форма буенча төзелгән, язма яки электрон рәвештә тапшырылган социаль хезмәт күрсәтү турында гаризасы яисә аның мәнфәгатьләрендә башка гражданнарның мөрәҗәгате, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләрнең турыдан-туры Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының яшәү урыны (тору урыны) буенча территориаль органына мөрәҗәгате яисә ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында бирелгән гариза яки мөрәҗәгать тора.

1.2.2. Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү турында карар кабул итү өчен кирәкле документлар шәхсән социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучы тарафыннан тапшырыла яисә «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 ел, 27 июль, ФЗ-210 нчы Федераль законның 7 статьясы таләпләре нигезендә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында бирелергә тиеш.

1.3. Социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган гражданнар социаль хезмәтләрдән файдалану өчен мөрәҗәгать иткәндә һәм социаль хезмәтләр күрсәткәндә аларны мәгълүмати тәэмин итүгә карата таләпләр

1.3.1. Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче стационар формада социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган гражданнарга (аларның законлы вәкилләренә) һәм социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларга (аларның законлы вәкилләренә) хокуклары һәм бурычлары, социаль хезмәтләрнең төрләре, социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү вакытлары, тәртибе һәм шартлары, әлеге хезмәтләргә тарифлар һәм социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган граждан (социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучы) өчен аларның кыйммәте турында яисә алардан түләүсез файдалану мөмкинлеге хакында һәркемгә ачык формада түләүсез мәгълүмат бирүне гамәлгә ашыра.

1.3.2. Мәгълүмат бирү социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче тарафыннан электрон элемтә яки телефон элемтәсе, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, мәгълүматны үзенең рәсми сайтында, социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче бинасында мәгълүмат стендларында, массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштыру, гражданнарны социаль хезмәтләр

күрсәтү белән тәэмин итүче биналарында шәхсән кабул иткәндә консультация бирү юлы белән, башка һәркемгә ачык ысуллар белән гамәлгә ашырыла.

Социаль хезмәтләр һәм аларны күрсәтүче социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр турында мәгълүмат «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 ел, 7 февраль, 2300-1 нче Россия Федерациясе Законы таләпләренә туры килергә тиеш.

Гражданнар социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең эше, социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат алу өчен шәхсән мөрәҗәгать иткәндә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче белгече тарафыннан кабул итүне көтүнең максималь вакыты 15 минут тәшкил итә.

1.3.3. Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 ел, 28 декабрь, ФЗ-442 нче Федераль законның 13 статьясы нигезендә үз эшчәнлеге турында мәгълүматлар булган һәркемгә ачык мәгълүмат ресурсы формалаштыра, әлеге ресурсны үз бинасындагы мәгълүмат стендларында, массакүләм мәгълүмат чараларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шул исәптән үзенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән аннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итә.

1.3.4. Социаль хезмәтләр турында дөреслеккә туры килмәгән, тиешле вакытында булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат бирүгә социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучылар (аларның законлы вәкилләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, шул исәптән суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

1.4. Социаль хезмәтләр күрсәтүнең куркынычсызлыгына карата таләпләр

1.4.1. Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче юридик зат буларак яисә индивидуаль эшмәкәр буларак теркәлгән һәм аның түбәндәге документлары булырга тиеш:

законнар нигезендә лицензияләнергә тиешле эшчәнлек төрләренә лицензияләр, рөхсәт кәгазьләре;

социаль хезмәтләр күрсәтү, аларны күрсәтүне контрольдә тотуны җайга салучы документлар;

законнар нигезендә булырга тиешле башка документлар.

Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче документларның актуальлеген, аларны үз вакытында яңартуны һәм иске документларны әйләнештән алуны даими контрольдә тотарга тиеш.

1.4.2. Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең биналары һәм бүлмәләре федераль законнарда билгеләнгән янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләренә, санитария-эпидемиология нормаларына, шулай ук федераль һәм республика законнары белән расланган башка нормаларга һәм таләпләргә туры килергә тиеш, шул исәптән санитария-гигиена нормалары һәм кагыйдәләре таләпләренә җавап бирергә һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатына тискәре йогынты ясый торган факторлардан (һаваның югары температурасы һәм дымлылыгы, тузанланган, газлар белән пычранган булу, тавыш, вибрация һ.б.) сакланган булырга тиешле бүлмәләрнең зурлыгы һәм торышы буенча.

1.4.3. Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче биналарының проект карарлары һәм җиһазлары социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның иминлеген, шул исәптән гадәттән тыш хәлләрдә һәркем файдалана алырлык һәм куркынычсыз эвакуацияне тәэмин итәргә тиеш.

1.4.4. Җиһазлар, приборлар, аппаратура, инвентарь законнар нигезендә санитария-эпидемиология кагыйдәләре һәм нормативлары таләпләренә, шулай ук Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән продукциянең куркынычсызлыгына карата таләпләргә җавап бирергә, эксплуатация документлары нигезендә алардан төгәл билгеләнеше буенча файдаланырга, техник яктан төзек хәлдә булырга һәм аларны системалы рәвештә тикшереп торырга тиешләр.

1.4.5. Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә аны гамәлгә кую документларында билгеләнгән функцияләрне үтәү, социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның хокукларын һәм ирекләрен саклау өчен җавап бирә.

1.4.6. Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучылар (аларның законлы вәкилләре) социаль хезмәтләр күрсәткәндә мәгълүм булган шәхси характердагы мәгълүматның конфиденциальлегенә хокуклы.

1.5. Социаль хезмәт күрсәтүне кадрлар белән тәэмин итү дәрәҗәсенә таләпләр

1.5.1. Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең социаль хезмәтләрне сыйфатлы итеп күрсәтү өчен кирәкле санда персоналы булырга тиеш.

1.5.2. Тиешле квалификация белән беррәттән социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче хезмәткәрләре социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның үзләренә карата ихтирамлы һәм гуманлы мөнәсәбәткә хокукларын сакларга тиеш.

1.5.3. Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче хезмәткәрләре социаль хезмәтләр күрсәткәндә гамәлгә кую документларында каралган таләпләрне, социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен үтәргә, вазыйфа инструкцияләре нигезендә аңа йөкләнгән функциональ бурычларны сыйфатлы итеп башкарырга, һөнәри этиканы төгәл үтәргә тиеш.

1.5.4. Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче хезмәткәрләре социаль хезмәтләрне аларның бурычларын, хокукларын һәм җаваплылыгын билгели торган вазыйфа инструкцияләре нигезендә күрсәтә.

1.6. Социаль хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен исәпләү

1.6.1. Социаль хезмәтләр күрсәтү шартларын билгеләү (түләүсез яисә түләүле яки өлешчә түләүле), социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучының уртача җан башына керемен исәпләү һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен исәпләү законнар таләпләре нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүгә кабул иткәндә гамәлгә ашырыла һәм социаль хезмәтләр күрсәтү процессында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең җан башына уртача кереме үзгәрү һәм (яки) түләүсез социаль хезмәтләр күрсәтү өчен Татарстан Республикасында билгеләнгән җан башына уртача керем күләме үзгәрү турында мәгълүматлар алганда законнарда билгеләнгән тәртиптә яңадан карап тикшерелә.

1.6.2. Социаль хезмәтләр күрсәтү өчен социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче ала торган түләү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен һәм аны алу тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 ноябрь, 927 нче карары нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы шартнамәдә билгеләнә.

1.7. Социаль хезмәтләр күрсәтүне туктату өчен нигезләр

1.7.1. Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүне туктату өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

1) социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучының (аның законлы вәкиленең) социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүдән баш тарту турында язма гаризасы;

2) социаль хезмәтләр күрсәтү буенча индивидуаль программа нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтү вакыты тәмамлану һәм (яки) социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы шартнамәнең гамәлдә булу вакыты чыгу;

3) социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучының (аның законлы вәкиленең) социаль хезмәтләр күрсәтү турында шартнамәдә каралган шартларны бозуы;

4) социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучының үлеме яки социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең ябылуы (эшчәнлеген туктату);

5) социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыны хәбәрсез югалган яки үлгән дип тану турында суд карары;

6) социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыны ирегеннән мәхрүм итү рәвешендә хөкемгә тарту;

7) социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучының вәкаләтле медицина оешмасы бәяләмәсе белән расланган медицина ягыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдалануына каршы килә торган күрсәткечләре барлыкка килү;

8) Россия Федерациясе территориясендә качак дип тану турында үтенечнамәне карап тикшерү хакында шаһәдатнамәнең, Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча качу урыны бирү турында гаризаны карап тикшерү турында белешмәнең яки Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча качу урыны бирү турында таныклыкның гамәлдә булу вакыты чыгу, әгәр аларның гамәлдә булу вакыты чыккан көнгә кадәр тиешенчә качак таныклыгы, Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча качу урыны бирү турында таныклык яки гамәлдә булу вакыты озайтылган Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча качу урыны бирү турында таныклык бирелмәсә;

9) Россия Федерациясе гражданы булмаган социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучының качак статусын югалтуы яки аны качак статусыннан мәхрүм итү;

10) Украина территориясендә даими яшәүче һәм гадәттән тыш массакүләм тәртиптә Россия Федерациясе территориясенә килгән Украина гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар арасыннан социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучының Россия Федерациясендә вакытлыча качу урынын югалтуы яки аны Россия Федерациясендә вакытлыча качу урыныннан мәхрүм итү.

1.7.2. Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның медицина ягыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүдән

файдалануына каршы килә торган күрсәткечләре барлыкка килгәндә, аларга вәкаләтле медицина оешмасының тиешле бәяләмәне төзүе турында билгеле булган көнне, әмма бәяләмәне алган көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, алар бу турыда социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчегә хәбәр итәргә тиеш.

1.1.1 нче пунктның икенче абзацында күрсәтелгән качаклар арасыннан, шулай ук чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар арасыннан социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучылар 1.7.1 нче пунктның 9 һәм 10 пунктчаларында күрсәтелгән хәлләр барлыкка килү турында әлеге хәлләр килеп чыккан көнне социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчегә хәбәр итәргә тиеш.

## 1.8. Социаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен бәяләү

1.8.1. Социаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен бәяләү социаль хезмәтләр сыйфатын исәпкә алып гамәлгә ашырыла һәм үз эченә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүнең тулылыгын бәяләүне ала, шул исәптән күрсәтелә торган социаль хезмәтләрнең күләмен, социаль хезмәтләрне күрсәтү вакытын, әлеге Тәртиптә билгеләнгән һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең тулылыгын бәяләргә мөмкинлек бирә торган башка критерийларны исәпкә алып.

1.8.2. Социаль-көнкүреш хезмәтләре күрсәтү сыйфатын бәяләү үз эченә түбәндәгеләрне бәяләүне ала:

1) күләмнәре һәм башка яшәеш күрсәткечләре (биналар һәм бүлмәләр торышы, аларның уңайлылыгы) буенча социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче бирә торган торак мәйданны, ул социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучылар өчен яшәү уңайлыкларын тәэмин итәргә, шулай ук социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларны торак урыннарга (бүлмәләргә) урнаштырганда физик һәм психик халәтен, гадәтләрен, психологик яктан ярашуын исәпкә алырга тиеш (мөмкинлек булганда);

2) социаль хезмәтләр күрсәтү урыннарын, алар күләмнәре, урнашуы һәм конфигурациясе буенча социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның үзенчәлекләрен исәпкә алып, социаль хезмәтләрнең барлык төрләрен күрсәтү мөмкинлеген тәэмин итәргә, санитария-гигиена нормаларына һәм таләпләренә җавап бирергә тиеш;

3) җиһазлар һәм җайланмаларны, алар файдалану өчен уңайлы булырга, социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның физик халәтен исәпкә алып сайланган булырга, санитария-гигиена нормаларына җавап бирергә тиеш;

4) социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларга бирелә торган йомшак инвентарьны, ул җайлы булырга, социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның буена һәм үлчәмнәренә туры килергә, санитария-гигиена нормаларына һәм таләпләренә һәм (мөмкинлек булганда) аларның фасоны һәм төсе буенча ихтыяҗларга җавап бирергә тиеш;

5) туклануны, ул сыйфатлы продуктлардан әзерләнгән булырга, социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның калориялелек буенча ихтыяҗларын канәгатьләндерергә, билгеләнгән туклану нормаларына, санитария-гигиена таләпләренә һәм нормаларына туры килергә тиеш;

6) үз-үзләренә хезмәт күрсәтә алмаган социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларга күрсәтелә торган хезмәтләрне, алар социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларга кирәкле процедураларны сәламәтлегенә, физик яки

рухи газапларына бернинди зыян һәм уңайсызлыклар китермичә башкаруны тәэмин итәргә тиеш;

7) социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче тарафыннан күрсәтелә торган башка социаль-көнкүреш хезмәтләре.

1.8.3. Социаль-медицина хезмәтләре күрсәтү сыйфатын бәяләү үз эченә түбәндәгеләрне бәяләүне ала:

1) медицина күрсәтмәләрен, физик һәм психик халәтен исәпкә алып, социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларны карауны оештыру юлы белән аларның сәламәтлеген саклауга процедураларны үз вакытында һәм кирәкле күләмдә башкаруны;

2) сәламәтлек хәлендәге тайпылышларны билгеләү өчен социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларны системалы рәвештә күзәтеп торуны;

3) социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның сәламәтлеген саклауга бәйле процедуралар, савыктыру чаралары үткәрүне, алар җайлап һәм игътибарлылык белән, социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларга һичнинди зыян китермичә гамәлгә ашырылырга тиеш;

4) социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларга социаль-медицина мәсьәләләре буенча консультация бирү чараларын, алар социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның сәламәтлекләрен саклауга бәйле булган билгеле бер проблемаларын дөрес аңлауда һәм хәл итүдә квалификацияле ярдәм күрсәтүне тәэмин итәргә тиеш;

5) адаптив физик культура буенча шөгыльләнүдә ярдәм күрсәтүне, ул социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның уңайлы һәм сәламәтлеге өчен куркынычсыз физик күнегүләр комплексын сәламәтлекне ныгыту өчен аны системалы рәвештә эшләү максаты белән үзләштерүен тәэмин итәргә тиеш;

6) социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче тарафыннан күрсәтелә торган башка социаль-медицина хезмәтләре.

1.8.4. Социаль-психологик хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү үз эченә түбәндәгеләрне бәяләүне ала:

1) социаль-психологик консультация бирүне, ул социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларга шәхесара мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча, шул исәптән гаиләдәге низагларны кисәтү һәм җиңеп чыгу өчен квалификацияле ярдәм күрсәтүне тәэмин итәргә тиеш;

2) психологик ярдәм, аны күрсәтү социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыга эчке ресурсларын ачарга һәм мобилизацияләргә, килеп чыккан социаль-психологик проблемаларны хәл итәргә ярдәм итәргә тиеш;

3) социаль-психологик патронажлык итүне, ул социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларны системалы рәвештә күзәтеп тору нигезендә психик уңайсызлык, шәхси (шәхеснең эчке) яки шәхесара низагларны һәм социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның яшәү шартларын начарайта торган башка хәлләрне, аларга кирәкле социаль-психологик хезмәтләр күрсәтү максатларында, үз вакытында билгеләүне тәэмин итәргә тиеш;

4) социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче тарафыннан күрсәтелә торган башка социаль-психологик хезмәтләр.

1.8.5. Социаль-педагогик хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү үз эченә түбәндәгеләрне бәяләүне ала:

1) социаль-педагогик коррекцияләү, аны гамәлгә ашыру социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләрдән файдалана торган социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучылар мохтаҗ булган квалификацияле һәм нәтиҗәле педагогик ярдәм күрсәтүне тәэмин итәргә тиеш;

2) социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларда уңай кызыксынулар формалаштыруны, аларның ялын оештыруны, алар социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның социомәдәни һәм рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерүне, социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның белем дәрәҗәсен, аралашу даирәсен киңәйтүне, иҗади активлыгын арттыруны тәэмин итәргә тиеш;

3) социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче тарафыннан күрсәтелә торган башка социаль-педагогик хезмәтләр.

1.8.6. Социаль-хезмәт хезмәтләре күрсәтү сыйфатын бәяләү үз эченә түбәндәгеләрне бәяләүне ала:

1) инвалидларның (шул исәптән инвалид балалар) физик мөмкинлекләре һәм акыл сәләте нигезендә белем һәм (яки) квалификация алуын оештыру яки алуында булышлык күрсәтү белән бәйле хезмәтләр сыйфатын;

2) социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның хезмәт мөмкинлекләрен файдалану һәм аларны һәркем алырлык һөнәри күнекмәләргә, күнекмәләрнең җитәрлек һәм үз вакытында булына укыту-өйрәтү буенча үткәрелә торган чараларны;

3) эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү буенча үткәрелә торган чараларны;

4) социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче тарафыннан күрсәтелә торган башка социаль-хезмәт хезмәтләре.

1.8.7. Социаль-хокукый хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү үз эченә түбәндәгеләрне бәяләүне ала:

1) документларны рәсмиләштергәндә һәм яңадан алганда булышлык күрсәтүне, ул социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларга кирәкле документларның билгеләнешенә бәйле эчтәлеген аңлатуны, документларның текстын бәян итү һәм (кирәк булганда) язуны яки форма бланкларын тутыруны, теркәп җибәрелә торган хатлар язуны тәэмин итәргә тиеш;

2) социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларга юридик хезмәтләрдән файдалануда ярдәм күрсәтү нәтиҗәлелеген, ул социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучының хокукый проблемаларын үз вакытында һәм объектив хәл итүне тәэмин итәргә тиеш;

3) социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче тарафыннан күрсәтелә торган башка социаль-хокукый хезмәтләр.

1.8.8. Тереклек эшчәнлекләре чикләнгән социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның, шул исәптән инвалид балаларның коммуникатив потенциалын арттыру максатларында күрсәтелгән хезмәтләр сыйфатын бәяләү үз эченә түбәндәгеләрне бәяләүне ала:

1) инвалидларны (инвалид балаларны) тернәкләндерүнең техник чараларын кулланырга өйрәтүне, ул инвалидларның (инвалид балаларның) әлеге чаралардан мөстәкыйль рәвештә файдалану буенча гамәли күнекмәләрен үстерергә тиеш;

2) социаль-тернәкләндерү чаралары үткәрүне, ул социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучының җәмгыять белән үзара мөнәсәбәтләрен яхшыртырга тиеш;

3) тереклек эшчәнлекләре чикләнгән социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларны, шул исәптән инвалид балаларны көнкүрештә һәм җәмәгать урыннарында үз-үзеңне тоту күнекмәләренә өйрәтүне, ул социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучының мөстәкыйль, әйләнә-тирәләргә мөнәсәбәттә культуралы, әдәпле һәм хәерхаһлы шәхес буларак формалашуын, шулай ук көнкүреш шартларында үз-үзенә хезмәт күрсәтергә сәләтле шәхеснең эчке дисциплинасына өйрәтүне тәэмин итәргә тиеш;

4) социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче тарафыннан тереклек эшчәнлекләре чикләнгән социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның, шул исәптән инвалид балаларның коммуникатив потенциалын арттыру максатларында күрсәтелгән башка хезмәтләр.»;

II бүлекнең 2.2.1 нче пунктында «1.5 бүлекчәнең» сүзләрен «1.6 бүлекчә нигезләмәләренең» сүзләренә алмаштырырга;

III бүлекнең 3.2.1 нче пунктында «1.5 бүлекчәнең» сүзләрен «1.6 бүлекчә нигезләмәләренең» сүзләренә алмаштырырга;

Тәртипнең IV бүлегендә:

4.2 бүлекчәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Социаль хезмәтләрне түләүсез яисә өлешчә түләүле нигездә күрсәтү кагыйдәләре

Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр акыл үсеше артта калган балалар өчен балалар интернат йортларында, физик кимчелекләре булган балалар өчен интернат йортларында күрсәтелә:

балигъ булмаган социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларга – түләүсез;

акыл үсеше артта калган балалар өчен балалар интернат йортында, физик кимчелекләре булган балалар өчен интернат йортында тәрбияләнүчеләр арасыннан балигъ булган социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларга – түләүле яки өлешчә түләүле (гражданнарга социаль хезмәтләр күрсәтү нигезләре турында федераль законнар нигезендә билгеләнә торган күләмдә һәм әлеге Тәртипнең I бүлегендәге 1.6 бүлекчә нигезләмәләрен исәпкә алып), федераль законнарда каралган очраклардан тыш.»;

4.3.6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3.6. Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче түбәндәгеләрне башкара:

4 яшьтән алып 13 яшькәчә ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның; балигъ булган һәм суд тарафыннан хокукка сәләтсез дип танылган затларның опекуны вазыйфаларын;

14 яшьтән алып 17 яшькәчә ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның; балигъ булган һәм суд тарафыннан хокукка сәләте чикләнгән затларның попечителе вазыйфаларын.

Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау максатларында, социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче опека һәм попечительлек органнары, мәгариф өлкәсендә идарә итүче

органнар, сәламәтлек саклау белән идарә итү органнары һәм башка дәүләт органнары, оешмалар һәм хезмәтләр белән үзара хезмәттәшлек итә.»;

4.3.7 нче пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның физик һәм (яки) психик үсешендәге кимчелекләрне, шулай ук үз-үзләрен тотышындагы тайпылышларны компенсацияләү һәм (яки) коррекцияләүгә, шул исәптән инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитациясенең индивидуаль программасын, инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитациясенең индивидуаль программасын тормышка ашыруга юнәлдерелгән чаралар үткәрү;»;

4.4.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4.1. Акыл үсеше артта калган балалар өчен балалар интернат йортларында, физик кимчелекләре булган балалар өчен интернат йортларында балигъ булмаган социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларга социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында күрсәтелә торган социаль хезмәтләрнең исемнәре, тасвирламасы, күләмнәре, сыйфаты күрсәткечләре һәм нәтиҗәләрен бәяләү әлеге Тәртипкә теркәлгән 3 нче кушымтада китерелә.

Акыл үсеше артта калган балалар өчен балалар интернат йортларында, физик кимчелекләре булган балалар өчен интернат йортларында 18 яшьтән алып 23 яшькәчә социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларга социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында күрсәтелә торган социаль хезмәтләрнең исемнәре, тасвирламасы, күләмнәре, сыйфаты күрсәткечләре һәм нәтиҗәләрен бәяләү әлеге Тәртипкә теркәлгән 7 нче кушымтада китерелә.»;

4.4.2 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«18 яшькә җиткән социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучылар акыл үсеше артта калган балалар өчен балалар интернат йортларында, физик кимчелекләре булган балалар өчен интернат йортларында социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы нигезендә белем бирү оешмасын тәмамлаганчы, әмма күп дигәндә 23 яшькә кадәр торуларын һәм социаль хезмәтләрдән файдалануын дәвам иттерә алалар.»;

4.4.4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4.4. Акыл үсеше артта калган балалар өчен балалар интернат йортларында, физик кимчелекләре булган балалар өчен интернат йортларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативы социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның яшенә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.»;

V бүлекнең 5.2.2 нче пунктында «1.5 бүлекчәнең» сүзләрен «1.6 бүлекчә нигезләмәләренең» сүзләренә алмаштырырга;

VII бүлекнең 7.2.1 нче пунктында «1.5 бүлекчәнең» сүзләрен «1.6 бүлекчә нигезләмәләренең» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә теркәлгән 3 нче кушымта исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Акыл үсеше артта калган балалар өчен балалар интернат йортларында, физик кимчелекләре булган балалар өчен интернат йортларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында балигъ булмаган социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларга күрсәтелә торган социаль хезмәтләрнең исемнәре, тасвирламасы, күләмнәре, сыйфаты күрсәткечләре һәм нәтиҗәләрен бәяләү »;

әлеге карарга кушымта нигезендәге редакциядә Тәртипкә 7 нче кушымта өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\345.doc

Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә 7 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 6 июнь, 345 нче карары редакциясендә)

Акыл үсеше артта калган балалар өчен балалар интернат йортларында, физик кимчелекләре булган балалар өчен интернат йортларында 18 яшьтән алып 23 яшькәчә социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларга социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында күрсәтелә торган социаль хезмәтләрнең исемнәре, тасвирламасы, күләмнәре, сыйфаты күрсәткечләре һәм нәтиҗәләрен бәяләү

| Т/с | Социаль хезмәт исеме | Социаль хезмәтнең тасвирламасы | Социаль хезмәт күләме | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | үлчәү берәмлеге | саны | күрсәтү ешлыгы |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1. | Социаль-көнкүреш хезмәтләре: | | | | |
| 1.1. | Социаль хезмәтләр күрсәтү өчен мәйданнар бирү, шул исәптән: | Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларга социаль-көнкүреш, социаль-медицина, социаль-психологик, социаль-педагогик, социаль-хезмәт, социаль-хокукый хезмәтләр һәм коммуникатив потенциалны арттыру максатларында хезмәтләр күрсәтүне оештыру өчен мәйданнар бирү өчен мәйданнар бирү | кв.метр | 21 | социаль хезмәт күрсәтү чоры |
| 1.1.1. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган нормативлар нигезендә торак урыннар мәйданын бирү | Торак мәйдан күләмнәре һәм башка яшәеш күрсәткечләре (урынның торышы һәм уңайлылыгы) буенча санитария-гигиена нормаларына туры килергә һәм клиентларның яшәү уңайлылыгын тәэмин итәргә тиеш: | | | социаль хезмәт күрсәтү чоры |
| | | социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыга 2 һәм аннан күбрәк койка-урынлы бүлмәдә торак мәйдан бирү | кв.метр | 6 | |
| 1.2. | Торак урыннарны җыештыру | Урыннарны санитария-гигиена эшкәртү, шул исәптән: | эшкәртү | | социаль хезмәт күрсәтү чоры |
| | | җилләтү; | | 2 | көнгә |
| | | идән юу; | | 2 | көнгә |
| | | стеналарны, ишекләрне юу; | | 1 | көнгә |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | йомшак өслекләрне тузан суырткыч белән тузаннан чистарту; | | 1 | көнгә |
| | | тәрәзә төпләрен, рамнарны, җиһазларны, көнкүреш приборларын, җылыткыч батареяларын юу; | | 1 | көнгә |
| | | раковинаны, унитазны, ваннаны чистарту, дезинфекцияләү | | 1 | көнгә |
| | | Гомуми файдаланудагы урыннарны җыештыру, шул исәптән юу: | җыештыру | | |
| | | туклану урыннарындагы идәннәрне; | | 4 | көнгә |
| | | коридорлардагы идәннәрне; | | 2 | көнгә |
| | | бәдрәфләрне, душ, ванна бүлмәләрен; | | 2 | көнгә |
| | | тернәкләндерү һәм дәвалау чараларын, дәвалау-хезмәт һәм уку-өйрәтү эшчәнлеген, мәдәни һәм көнкүреш хезмәте күрсәтүне оештыру урыннарындагы идәннәрне; | | 1 | көнгә |
| | | тәрәзә пыялаларын һәм рамнарын | | 1 | айга |
| | | Тәрәзәләрне, балкон һәм керү ишекләрен көзге-кышкы һәм язгы-җәйге чорларда эксплуатацияләүгә әзерләү (җылыту, герметиклардан чистарту) | әзерләү | 2 | елга |
| | | Якын-тирә территорияне чүпчардан (кардан) чистарту. | чистарту | 1 | көнгә |
| 1.3. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган нормативлар нигезендә йомшак инвентарь һәм санитария-гигиена билгеләнешендәге әйберләр белән тәэмин итү | Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыны йомшак инвентарь (караватянына җәелә торган палас, сөлге, урын-җир әйберләре), санитария-гигиена билгеләнешендәге товарлар (туалет кәгазе, юа торган чаралар), өс киемнәре һәм аяк киемнәре белән тәэмин итү. Өс киемнәре һәм аяк киемнәре, сезонга карап, клиентның буе һәм үлчәме буенча сайлана.<br>Йомшак инвентарь файдаланудa уңай булырга, клиентларның физик хәлен исәпкә алып сайланырга тиеш. Йомшак инвентарь | данә (комплект) | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган нормативлар нигезендә | социаль хезмәт күрсәтү чоры |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | белән тәэмин иткәндә шулай ук урын-җир әйберләрен, өс киемнәрен юу, киптерү, үтүкләү, киемнәрне, урын-җир әйберләрен һәм эчке киемнәрне дезинфекцияләү, урын-җир әйберләрен (матрац, юрган, мендәр, япма) дезинфекцияләү, шул исәптән социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучы социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчедән киткәннән соң урын-җир әйберләрен алыштыру, тернәкләндерүнең шәхси техник чараларын, протезларны, ортезларны һәм башкаларны карауда ярдәм күрсәтү, аяк киемнәрен үзәкләштереп ремонтка бирү | | | |
| 1.4. | Сәламәтлекләренең торышы буенча мөстәкыйль рәвештә үз-үзләренә гигиена хезмәтләре күрсәтә алмаган затларга аларны күрсәтү | Эчке киемнәрне алыштыру; | алыштыру | кимендә 1 тапкыр | атнага (социаль хезмәт күрсәтү чоры) |
| | | индивидуаль хезмәт күрсәтү һәм гигиена характерындагы социаль-көнкүреш хезмәтләре күрсәтү, шул исәптән: | хезмәтләр күрсәтү | даими | социаль хезмәт күрсәтү чоры |
| | | социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыга урын-җир өстендә борылып ятарга, урынын алыштырырга ярдәм итү; | | | көн саен |
| | | киенгәндә (чишенгәндә) ярдәм итү; | | | көн саен |
| | | урын-җирен җыештыру; | | | көн саен |
| | | юындыру; | | 1 | көнгә |
| | | чәчләрен тарау; | | 1 | көнгә |
| | | чәчтараш хезмәтләре күрсәтүне оештыру; | | 1 | айга |
| | | сакалын, мыегын кыру (ир-атларга); | | 1 | атнага |
| | | тырнакларын кисү; | | 1 | атнага |
| | | авыз куышлыгын, борын куышлыгын, күзләрен, колакларын юдыру, медицина препаратлары белән эшкәртү; | | 1 | көнгә |
| | | тәнне өлешчә чистарту (юеш сөлге белән сөртү, юу, гигиена | | 1 | көнгә |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | ванналары); | | | |
| | | тәнне тулысынча чистарту: ятып кына торучы авыруны мунчада (ваннада, душта) тулысынча юындыру; | | 1 | атнага |
| | | судноны түгү һәм антисептик препаратлар белән эшкәртү; | | факт буенча | көн саен |
| | | катетерлардан һәм башка медицина әйберләреннән файдалануда ярдәм итү | | факт буенча | көн саен |
| 1.5. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган нормалар нигезендә туклану белән тәэмин итү | Кайнар аш сыйфатлы продуктлардан әзерләнергә, калориясе буенча клиентлар ихтыяҗларын канәгатьләндерергә, туклануның билгеләнгән нормаларына, санитария-гигиена таләпләренә туры килергә һәм социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучының сәламәтлеге торышын исәпкә алып күрсәтелергә тиеш | ризык кабул итү | 4 | тәүлеккә |
| 1.6. | Ризык кабул итәргә булышу (ашату) | Оештырылган туклану вакытында ашату | ашату | кирәк булганда | тәүлеккә |
| 1.7. | Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучы акчасы исәбеннән почта корреспонденциясе җибәрү | Хатлар әйтеп яздыру, хатларны, телеграммаларны кычкырып уку, социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучы акчасы исәбеннән почта корреспонденциясе җибәрү һәм алу | хезмәтләр күрсәтү | заявка буенча | социаль хезмәт күрсәтү чоры |
| 1.8. | Медицина оешмаларына транспортка утыртып илтүне оештыру | Кичектергесез медицина ярдәме күрсәтергә кирәк булган очракта йә дәвалау учреждениесенә салуны таләп итә торган авыру килеп чыкканда, госпитальләштерүдә булышлык күрсәтү | ашыгыч медицина ярдәмен чакыру яисә дәвалау-профилактика учреждениесенә илтү | күрсәткечлр буенча | социаль хезмәт күрсәтү чоры |
| 2. | Социаль-медицина хезмәтләре: | | | | |
| 2.1. | Табиб тарафыннан медицина каравын үткәрү | Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучының сәламәтлеге торышын объектив билгеләү өчен хезмәт күрсәтүгә кабул итү өчен | караулар | 1 | елга (социаль хезмәт күрсәтү чоры) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | яраганлык күрсәткечләре булу (булмауны) ачыклау буенча беренчел медицина каравын үткәрү | | | |
| 2.2. | Табиб билгеләве буенча медицина процедуралары үткәрү | Дару тамызу; тәнне сылау; горчичниклар, компресслар кую; дару препаратларын тире астына һәм мускул эченә кертү; яраны эшкәртү һәм бәйләү; суелган урыннарны эшкәртү | процедуралар | табиб билгеләве буенча | социаль хезмәт күрсәтү чоры |
| 2.3. | Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучылар сәламәтлегендәге тайпылышларны ачыклау өчен аларны системалы рәвештә күзәтеп тору | Шәфкать туташы тарафыннан карау (сәламәтлек торышын күзәтү) | караулар | 1 | көнгә |
| 2.4. | Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучылар сәламәтлеге торышын күзәтүгә бәйле булган процедуралар үткәрү | Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның сәламәтлеге торышын күзәтүгә бәйле булган процедуралар үткәрү: | | | социаль хезмәт күрсәтү чоры |
| | | тән температурасын үлчәү; | процедуралар | күрсәткечләр буенча | |
| | | артериаль кан басымын үлчәү; | процедуралар | күрсәткечләр буенча | |
| | | дарулар кабул итүне тикшерүдә тоту | процедуралар | табиб билгеләве буенча | |
| 2.5. | Савыктыру чараларын үткәрү | Иртән гимнастика ясауны, саф һавада йөреп керүне, һава ванналарын кабул итүне оештыру | чаралар комплексы | 1 | көнгә (социаль хезмәт күрсәтү чоры) |
| 2.6. | Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга юнәлдерелгән чаралар үткәрү | Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру һәм төрле авыруларны профилактикалау мәсьәләләре буенча санитария-агарту эше; акыл хезмәте һәм физик хезмәт башкару мөмкинлеген арттыру мотивацияләре | чаралар | 1 | айга (социаль хезмәт күрсәтү чоры) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 2.7. | Адаптив физик культура буенча дәресләр үткәрү | Компенсатор күнекмәләрен формалаштыруга юнәлдерелгән спорт-савыктыру характерындагы чараларны оештыру һәм үткәрү; тулы канлы тормыш алып баруга комачаулый торган физик һәм психологик проблемаларны җиңү | хезмәтләр күрсәтү | 2 | атнага (социаль хезмәт күрсәтү чоры) |
| 2.8. | Социаль-медицина мәсьәләләре буенча консультацияләр үткәрү | Сәламәтлек саклау һәм аны тиешле формада тоту мәсьәләләре, савыктыру чараларын үткәрү буенча консультацияләр үткәрү, социаль-медицина проблемаларын хәл итүдә (кешеләрнең үзүзләрен тотышындагы девиациядән, зарарлы гадәтләрдән арыну һ.б.) квалификацияле ярдәм күрсәтү | консультацияләр | 1 | айга (социаль хезмәт күрсәтү чоры) |
| 3. | Социаль-психологик хезмәтләр: | | | | |
| 3.1. | Социаль-психологик консультация үткәрү, шул исәптән гаилә эчендәге мөнәсәбәтләр мәсьәләләре буенча | Шәхеснең эчке проблемаларын, шәхесара үзара бәйләнеш проблемаларын хәл итүдә квалификацияле ярдәм күрсәтү, социаль-психологик проблемаларны кисәтү һәм җиңү, шул исәптән бу проблемаларны хәл итү өчен эчке ресурсларны мобилизацияләү юлы белән | консультацияләр | 1 | елга (социаль хезмәт күрсәтү чоры) |
| 3.2. | Психологик ярдәм һәм булышлык күрсәтү | Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучы шәхесе үзенчәлекләре җыелмасын тикшерү, тереклек эшчәнлегенең бозылган өлкәләрен компенсацияләү яки тергезү шартларын билгеләү, социаль-психологик ярдәм чаралары исемлеген эшләү | чаралар комплексы | 2 | елга (социаль хезмәт күрсәтү чоры) |
| 4. | Социаль-педагогик хезмәтләр: | | | | |
| 4.1. | Социаль-педагогик коррекцияләү, диагностика һәм консультация үткәрүне кертеп | Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучының социаль дезадаптациясен диагностикалау, тереклек эшчәнлегенең бозылган өлкәләрен компенсацияләү яки төзәтү шартларын билгеләү | чаралар комплексы | 2 | елга (социаль хезмәт күрсәтү чоры) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучының шәхесе үзенчәлекләрен һәм сыйфатын педагогик ысуллар белән максатчан үзгәртү; шәхеснең тулы канлы үсешен һәм эшчәнлеген тәэмин итү максатыннан чыгып, үзенчәлекле ярдәм күрсәтү, үз-үзен тотышындагы кимчелекләрне төркемнәрдә яки индивидуаль рәвештә бетерү һәм профилактикалау (күрсәткечләр буенча) | курслар | 2 | елга (социаль хезмәт күрсәтү чоры) |
| 4.2. | Позитив мәнфәгатьләр булдыру | Күңел ачу-танып-белү характерындагы күмәк чаралар (әдәби кичәләр, очрашу һәм искә алу кичәләре, төрле даталарны бәйрәм итү) оештыру; | чаралар | 1 | атнага (социаль хезмәт күрсәтү чоры) |
| | | социомәдәни эшчәнлек, иҗади методлар белән рекреация чараларын оештыру һәм үткәрү, мөмкинлегенә-сәләтенә карап дәресләр (музыка, сынлы сәнгать, әдәбият, үзешчән сәнгать, гамәли характердагы дәресләр) оештыруда булышлык күрсәтү | чаралар | 2 | атнага (социаль хезмәт күрсәтү чоры) |
| 4.3. | Буш вакытны оештыру | Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучы акчасы исәбеннән китаплар, журналлар, газеталар, өстәл уеннары белән тәэмин итү; | чаралар | заявка буенча | социаль хезмәт күрсәтү чоры |
| | | концертларга, театрларга, экскурсияләргә, күргәзмәләргә баруны, социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче чикләреннән читтә урнашкан урыннарга барып, башка чаралар оештыру | чаралар | 1 | яртыеллыкка (социаль хезмәт күрсәтү чоры) |
| 5. | Социаль-хезмәт хезмәтләре: | | | | |
| 5.1. | Хезмәт мөмкинлекләреннән файдалану һәм алар үзләштерә ала торган һөнәри күнекмәләргә өйрәтү чараларын үткәрү | Медицина бәяләмәсе нигезендә, сәламәтлекләре торышын, мәнфәгатьләрен, теләкләрен исәпкә алып, дәвалау-хезмәт эшчәнлеген оештыру, булдыра алырлык һөнәри күнекмәләргә һәм хезмәт күнекмәләренә (инструментлар белән эш итәргә һәм гади операцияләр башкарырга, хисаплау һәм үлчәү күнекмәләрен формалаш- | чаралар | 3 – 5 (табиб күрсәткечләре буенча) | атнага (социаль хезмәт күрсәтү чоры) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | тырырга, компьютердан һәм электрон мәгълүмат ресурсларыннан файдаланырга) өйрәтү (күрсәтмәләр буенча) | | | |
| 5.2. | Инвалидларның сәләтләренә карап белем һәм (яки) һөнәр алуына ярдәм оештыру | Инвалидларның белем алуын оештыруда булышлык күрсәтү, аларның үзбилгеләнүенә ярдәм күрсәтү, төрле эшчәнлек төрләре белән кызыксынуларын һәм аларга һәвәслеген түбәнде юллар белән билгеләү:<br>һөнәри ориентация чаралары оештырып һәм үткәреп;<br>социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучының кызыксынулары һәм мөмкинлекләре нигезендә һөнәри эшчәнлек төрен сайлауда ярдәм итеп;<br>инвалидларга белем бирүне гамәлгә ашыручы (дәүләт, муниципаль) мәгариф оешмалары турында мәгълүмат биреп;<br>белем бирү оешмалары белән хезмәттәшлек итеп; белем бирү оешмаларына мөрәҗәгать итеп;<br>уку өчен документлар җыюда булышлык күрсәтеп | чаралар комплексы (индивидуаль билгеләнә) | кирәк булганда | социаль хезмәт күрсәтү чоры |
| 5.3. | Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү | Халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт органнары аша эшкә урнашу мәсьәләсен хәл итүдә булышлык күрсәтү (сәламәтлеге торышы буенча хезмәт эшчәнлеге белән шөгыльләнү мөмкинлеге турында табиб бәяләмәсе нигезендә) | чаралар комплексы | 1 | социаль хезмәт күрсәтү чоры |
| 6. | Социаль-хокукый хезмәтләр: | | | | |
| 6.1. | Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның документларын рәсмиләштергәндә һәм яңадан алганда булышлык күрсәтү | Карамагында кирәкле мәгълүмат булган оешмаларга сорату җибәрү юлы белән документларны яңадан алуда булышлык күрсәтү | хезмәтләр күрсәтү | кирәк булганда | социаль хезмәт күрсәтү чоры |
| 6.2. | Юридик хезмәтләр күрсәтүдән файдалануда ярдәм итү | законнарда билгеләнгән тәртиптә адвокатның түләүсез ярдәмен алуда булышлык күрсәтү, шул исәптән хокукка сәләтсез гражданнарның законлы хокук- | хезмәтләр күрсәтү | кирәк булганда | социаль хезмәт күрсәтү чоры |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | ларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү максатларында | | | |
| 7. | Тереклек эшчәнлекләре чикләнгән социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның коммуникатив потенциалын арттыру максатларында хезмәтләр күрсәтү: | | | | |
| 7.1. | Инвалидларны үз-үзләрен карау чараларыннан һәм тернәкләндерүнең техник чараларыннан файдаланырга өйрәтү | Инвалидларның үз-үзләрен карау чараларыннан һәм тернәкләндерүнең техник чараларыннан мөстәкыйль рәвештә файдалану буенча гамәли күнекмәләрен үстерү буенча дәресләр үткәрү | дәресләр | кирәк булганда | социаль хезмәт күрсәтү чоры |
| 7.2. | Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль-тернәкләндерү чараларын үткәрү | Инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитациясенең индивидуаль программасын тормышка ашыру кысаларында, социаль-педагогик, социаль-психологик, социомәдәни, социаль-көнкүреш тернәкләндерүен, физкультура-савыктыру чараларын, ул булдыра ала торган социаль-мохит күнекмәләренә, үз-үзен тикшерүдә тотуга, шәхси саклануга, аралашу күнекмәләренә һәм тереклек эшчәнлегенең башка формаларына өйрәтүне кертеп, җитешсезлек тибын һәм структурасын, үсешендәге индивидуаль психофизик һәм шәхси үзенчәлекләрне исәпкә алып, төркемнәрдә (7 кешегә кадәр) яки индивидуаль рәвештә (күрсәткечләр буенча) социаль-мохит тернәкләндерүен үткәрүне тәэмин итү | дәресләр | 1 | көнгә (социаль хезмәт күрсәтү чоры) |
| 7.3. | Үз-үзләренә хезмәт күрсәтү, көнкүрештә һәм җәмәгать урыннарында үз-үзләрен тоту күнекмәләренә өйрәтү | Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучының үз-үзенә хезмәт күрсәтү, шул исәптән тернәкләндерүнең техник чараларыннан файдаланып, көнкүрештә һәм җәмәгать урыннарында үз-үзен тоту күнекмәләренә, осталыкларына ия булуы (камилләштерү) максатыннан чыгып, җитешсезлек тибын һәм структурасын, үсешендәге индивидуаль психофизик һәм шәхси үзенчәлекләрне исәпкә алып, төркемнәрдә (7 кешегә кадәр) яки индивидуаль рәвештә (күрсәткечләр буенча) белем бирү һәм үстерү характерындагы чаралар үткәрү | дәресләр | даими | социаль хезмәт күрсәтү чоры |

Акыл үсеше артта калган балалар өчен балалар интернат йортларында, физик кимчелекләре булган балалар өчен интернат йортларында 18 яшьтән алып 23 яшькәчә социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларга социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен бәяләү һәм аларның сыйфаты күрсәткечләре

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | Хисаплап чыгару формуласы | Мәгълүмат чыганагы | Индикаторның чик мәгънәсе | Индикаторның үлчәү коэффициенты |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| Торак мәйданның бер койка-урынга туры килә торган факттагы күләменең норматив мәйданга карата мөнәсәбәте | процент | $\frac{Пжф / Ккм}{Н}$, монда: Пжф – койка-урыннарның норматив буенча расланган санына факттагы суммар торак мәйдан; Ккм – норматив буенча расланган койка-урыннар саны; Н – бер койка-урынга норматив торак мәйдан | Росстатның 2009 ел, 11 сентябрь, 196 нчы боерыгы белән расланган дәүләт статистика хисаплылыгының 3-собес формасы | 100 | 8 |
| Социаль хезмәтләр күрсәткәндә санитария-гигиена режимын бозулар булу | берәмлек | контроль-күзәтчелек органнары күрсәтмәләрендә теркәлгән тәртип бозулар булу | тикшерү акты | 0 | 8 |
| Турыдан-туры социаль хезмәтләр күрсәтүче аттестацияләнгән, аккредитацияләнгән, сертификацияләнгән хезмәткәрләрнең аттестацияләнергә, аккредитацияләнергә, сертификацияләнергә тиешле мондый хезмәткәрләр гомуми санындагы өлеше | процент | $\frac{АР}{ОКР} \times 100$, монда: АР – социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмада аттестацияләнгән, аккредитацияләнгән, сертификацияләнгән хезмәткәрләр; ОКР – штат расписаниесе буенча аттестацияләнергә, аккредитацияләнергә, сертификацияләнергә тиешле вазыйфаларның гомуми саны | мониторинг системасы | 100 | 3 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| Хезмәт терапиясе тәкъдим ителгән социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның гомуми саныннан хезмәт терапиясенә җәлеп ителгән социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучылар өлеше | процент | (Чотт / Чртт) х 100, монда: Чотт – хезмәт терапиясенә җәлеп ителгән социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучылар саны; Чртт – хезмәт терапиясе тәкъдим ителгән социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның гомуми саны | Росстатның 2009 ел, 11 сентябрь, 196 нчы боерыгы белән расланган дәүләт статистика хисаплылыгының 3-собес формасы | 80 | 9 |
| Белем алырга тәкъдим ителгән социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның гомуми саныннан психология-медицина-педагогика комиссиясе тәкъдим иткән программалар буенча белем бирү процессына җәлеп ителгән социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучылар өлеше | процент | (Чотт / Чртт) х 100, монда: Чотт – белем бирү процессына җәлеп ителгән социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучылар саны; Чртт – белем алырга тәкъдим ителгән социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның гомуми саны | мониторинг | 100 | 10 |
| Социаль хез-мәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның нигезле шикаятьләре өлеше | процент | $\frac{Жо}{Ж} \times 100$, монда: Жо – социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның хисап чорында кергән нигезле шикаятьләре саны; Ж – социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның хисап чорында кергән шикаятьләре гомуми саны | социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучылар шикаятьләрен һәм алар буенча күрелгән чаралар турындагы мәгълүматларны анализлау | 0 | 8 |
| Социаль хезмәтләрнең сыйфаты һәм һәркем файдалана алырлык булуыннан канәгать социаль хез- | процент | $\frac{(Ок + Од)}{2 \times О} \times 100$, монда: Ок – хезмәтләр сыйфатыннан канәгать булган сораштырылган- | социаль хезмәтләрдән файдаланучыларны сораштыру нәтиҗәләре буенча | 100 | 7 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| мәтләр күрсәтүдән файдаланучылар өлеше | | нар саны;<br>Од – хезмәтләрнең һәркем файдалана алырлык булуыннан канәгать булган сораштылганнар саны;<br>О – сораштырылганнарның гомуми саны | | | |
| Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең штаты комплектланган булу | процент | $\frac{УС}{ЧСШ} \times 100,$<br>монда:<br>УС – социаль хезмәтләр күрсәтү оешмасында эшләүче белгечләр саны;<br>ЧСШ – штат расписаниесе буенча белгечләр ставкалары саны | мониторинг системасы | 100 | 3 |
| Профильле һөнәри белеме булган белгечләр өлеше | процент | $\frac{ПО}{ОКС} \times 100,$<br>монда:<br>ПО – профильле һөнәри белеме булган белгечләр саны;<br>ОКС – белгечләрнең гомуми саны | мониторинг системасы | 100 | 3 |
| Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен нигез булып торган документлардан һәркем файдалана алу дәрәҗәсе | процент | $\frac{ОД}{ОКД} \times 100,$<br>монда:<br>ОД – социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен нигез булып торган һәм алар белән социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучы танышу мөмкинлеге тәэмин ителгән документлар саны;<br>ОКД – социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен нигез булып торган документларның (устав (нигез- | тикшерү нәтиҗәләре буенча | 100 | 6 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | ләмә); кулланмалар, кагыйдәләр, тәгълимнамәләр, социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучылар белән эшләү һәм үз эшчәнлекләре буенча методикалар; җиһазларга, приборларга һәм аппаратурага эксплуатация документлары һәм башка документлар) гомуми саны | | | |
| Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче урыннарының махсус һәм техник җиһазлар (җиһазлар, приборлар, аппаратуралар) белән тәэмин ителү дәрәҗәсе | процент | $\frac{КТ}{ОКТ} \times 100$, монда: КТ – эшләп тора торган җиһазлар, приборлар, аппаратуралар саны; ОКТ – социаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле җиһазлар, приборлар, аппаратуралар саны | тикшерү нәтиҗәләре буенча | 100 | 5 |
| Социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе һәм кагыйдәләре турындагы мәгълүмат торышы | булу/ булмау | социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең мәгълүмат стендларында һәм сайтында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе һәм кагыйдәләре турында актуаль мәгълүмат булу | тикшерү нәтиҗәләре буенча | 100 | 5 |
| Социаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатының эчке системасы булу | булу/ булмау | социаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатының расланган эчке системасы булу (социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче приказы, социаль хезмәт күрсәтү сыйфатына эчке контроль оештыру документларының исәпкә алу формалары) | мониторинг системасы | булу | 4 |
| Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең урнашу шартлары һәркем өчен файдалана алыр- | процент | $\frac{КДЗ}{ОКЗ} \times 100$, монда: КДЗ – инвалидлар һәм башка затлар керә алырлык булган һәм | социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең структур-функциональ | 80 | 4 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| лык булу дәрәҗәсе | | аларның тереклек эшчәнлекләрендәге чикләнүләр исәпкә алынган структур-функциональ зоналар саны;<br>ОКЗ – структур-функциональ зоналарның гомуми саны | зоналарын тикшерү нәтиҗәләре буенча | | |

F:\KARAR\2017\345_1.doc